# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“30” март 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 30 мартында 11 сәгать 00 минутта узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән түбәндәге сорау буенча беркетмә төзелде:

Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чембулат торак пунктында гражданнар Җыененың 15.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү:

«2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Чембулат авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
2) янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын төзү, ремонтлау (Чембулат авылында янгын сүндерү сулыгы урнаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)»

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 85 (иксән биш) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 46 (кырык алты) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 46 (кырык алты) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2.“Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлегенең Чембулат торак пунктында гражданнар Җыененың 15.11.2023 ел №2 карарына үзгәрешләр кертү, карарның 2 пунктын түбәндәге эчтәлектәге яңа редакциядә бәян итү” :

«2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Чембулат авылы территориясендә агач һәм куакларны чистарту, кисү, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) янгынга каршы резервуарларны (янгын сүндерү сулыкларын), янгын сүндерү пирсларын төзү, ремонтлау (Чембулат авылында янгын сүндерү сулыгы урнаштыру, материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)» мәсьәләсе буенча карарны танырга.

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Яңа Шашы авыл җирлеге Чембулат авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Яңа Шашы авыл җирлеге башлыгы Сабирҗанов М.С.

Совет Новошашинского сельского поселения
Яңа Шашы авыл җирлеге Советы